**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының 11сыйныфында укучылар өчен олимпиада сораулары**

Үткәрү вакыты 120 мин.

**I бүлек**

| Бирелгән сорауларга дөрес җавапларны күрсәтегез |
|---|

1. **“Мәхәббәт тәүбәсе” (Һ.Такташ) әсәренең жанры:**
   а) роман ә) поэма
   б) драма в) шигырь

2. **Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучы:**
   а) Фәнис Яруллин
   ә) Ф.Әмирхан
   б) Фатих Кәрим
   в) Хәсән Туфан

3. **Фатих Кәримнеке булмаган әсәр:**
   а) Разведчик язмалары
   б) Сибәли дә сибәли
   в) Кошчык

**II бүлек**

| Роман жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. |
|---|

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

**III бүлек**

| М.Мәһдиев иҗаты белән бәйле сорау-биремнәргә җавап языгыз |
|---|

1. М.Мәһдиевнең дүрт әсәрен санагыз

2. Ф.Миңнуллин М.Мәһдиев иҗатына бәя биреп, “яшьлеген сагынучы әдип”, дип язды. Тәнкыйтьченең бу фикерен ничек аңлыйсыз?

3. “Бәхилләшү”, яки “Кеше китә – җыры кала” әсәрендә сурәтләнгән чорга бәя бирегез

4. Әдипнең күп әсәрләре “тартмалы композиция”гә нигезләнгән. Әлеге төшенчәне аңлатыгыз

5. “Кеше китә – җыры кала” дигән исемгә салынган мәгънәне аңлатыгыз

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

“Юк, Сәрвәр, безгә кавышу насыйп булмас. ... Безне аерырлар. Мин төшемдә шулай күрдем. Өч тапкыр шул бер үк төшне күрдем. Күзге караңгы төн, имеш. Күктәге йолдызлар шундый яктылар, имеш. Бер урында бик күп егетләр җыелганнар икән дә һәркайсы үзенә берәр йолдыз алганнар икән. Син дә шул арада үзеңә йолдыз сайлагансың, ди. Мәхдүм дә сайлаган, минем дә йолдызым бар икән. Менә кинәт аждаһа төсле бернәрсә сызгырды да, йолдызларны сүндерә башладылар. Минем йолдызым да сүнде, мәхдүмнең дә, синең йолдыз да сүнде. Тагын бик күп, бик күп егетләрнең йолдызлары сүнеп, күк йөзе корымлы кара таба төсле караңгыланып, каралып калды.

Сәрвәр *(елап)*. Җитәр, җитәр, җитәр... Юк, юк, бу — ялган төш, бу дөрес түгел”.

1. Драманың авторын һәм исемен күрсәтегез________________________

____________________________________________________________

2. Төш күрүченең исемен атагыз. Сюжет сызыгында төш күрү вакыйгасының урыны нинди? Сүз нәрсә турында бара. Аңлатыгыз.

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
_________________________________________________________________

3. Сәрвәр, Исмәгыйльгә хас сыйфатларны санагыз һәм шуңа бәйләп төп идеяне ачыгыз

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

## IV бүлек

IV бүлек биремнәренә җавап язызыз

X. Туфанның “Ромашкалар” шигырендә кулланылган метафораны табыгыз. Ул ни өчен кулланылган, аңлатыгыз.

Юк ромашка,
Минем йөрәкнең
Януларын баса алмыйсың
Сөя әле, сагына һаман, дип,
Алдыйсың ич мине, алдыйсың.

## V бүлек

11 сыйныфта укыган әсәрләрдән мисаллар китереп, ике яшь кеше арасындагы мәхәббәт хакында фикерләрегезне инша итеп языгыз